**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Нармонка авыл җирлегенең Нармонка торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**03 декабрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегенең Нармонка торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Нармонка авыл җирлегенең Нармонка торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, иректән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Нармонка авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау;

-Нармонка авылының су башнясы территориясен койма белән әйләндереп алу.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **Т.А. Хакимов**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Нармонка авыл җирлеге башлыгы** **Т.А. Хакимов**